Вакытлы матбугатта Тукай темасы куелышын өйрәнүне эзлекле рәвештә дәвам итәргә кирәк. Газета вакыт белән бергә атлаучы матбугат чарасы ул. Матбугат төпләнмәләреннән халыкның тормышы көзгедәге кебек күренеп тора. Монда чын мәгънәсендә шагыйрьгә карата мөнәсәбәтне билгеләргә була. Тукай шәхесенә караш төрлечә булган. Газетаның кайбер елларында, шул ук сугыш чоры төпләнмәләрендә дә Тукай исеме күренми диярлек. Үзгәртеп кору елларыннан соң шагыйрьгә карата игътибар арткан. Бу халыкның милли үзаңы уяну белән дә бәйле күренеш була. Соңгы вакытта Тукайга мөнәсәбәтле проблемалы язмалар да шактый күп күренә башлады. Шул ук вакытта вакытлы матбугатта Тукай темасына аның үлеме һәм тууына бәйле түгәрәк даталарда яки туган көннәрендә генә мөрәҗәгать итү ачык күренә. Бу татар милләтенең Тукайга мөнәсәбәтен чагылдыра кебек. Газета һәм журналларда Тукай темасын яктыртучы даими рубрикалар булдырырга кирәк дигән фикер кала. Соңгы вакытта Тукай премиясе алыр вакыт җиткәч кенә Тукай исеме газеталарда пәйда була. Монысы бигрәк тә аяныч. Шуңа да публицистларның бу хакта язган кискен-кискен язмаларының да газетада басылып чыгуы да урынлы. Шул ук вакытта Язучылар берлегенә кергән өч йөздән артык язучы һәм шагыйрьнең ел дәвамында Тукайга карата язылган бер генә язмасы да матбугатта күренми.

«Ватаным Татарстан» газетасының архивын барлаганнан соң, вакытлы матбугатта Тукай темасының аерым урыны бар, дип әйтә алабыз. Татар басмасы Тукайга мөрәҗәгать итмичә кала алмый. Вакыт узган саен без тарихта калган язмаларның никадәр әһәмиятле икәнен аңлыйбыз.

**Әдәбият**

1. «Ватаным Татарстан». Газетаның 90 еллыгы уңаеннан истәлекләр, документлар, фоторәсемнәр. Казан, Идел-Пресс нәшрияты, 2009 ел. 224 б.

## ЯЗЫКОВЫЕ И СТИЛИСТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ ЭССЕ «ОСТАЗ» («НАСТАВНИК») М.МАГДИЕВА

**А.А. Гусейнова,**
ассистент
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия),
E-mail: aigel24@mail.ru

**Аннотация.** В работе рассмотрены особенности языка и стилистики жанра эссе в контексте ее актуальных функций, способствовавших развитию связей между читателем и автором. Результаты исследования могут быть использованы преподавателями и журналистами, обращающимися к изучению стиля, языка и жанра.

**Ключевые слова:** язык, стиль, жанр, эссе, факт, деталь, изобразительные средства, речь, публицистика

**Summary.**The paper discusses the features of the language and the style of the essay genre in the context of its current functions, contributing to the development of relations between the reader and the author. The results may be used by teachers and journalists applying to the style, language, and genre.

**Keywords:** language, style, genre, essay, fact, detail, graphic arts, speech, journalism.

## М.МӘҺДИЕВНЕҢ «ОСТАЗ» ЭССЕСЕНДӘ СТИЛЬ ҺӘМ ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ

Телнең үсүе дигәндә, бүген нәрсәне күз алдында тотабыз соң? Үскән тел нинди була? И.М.Низамов сүзләренчә, һәр иҗтимагый күренешнең үсү процессы кебек үк, телнең үсүе дә катлаулы, күп яклы һәм төрле-төрле сыйфатлар белән билгеләнә. Үткән гасырда иҗат иткән рус лингвисты Н.В.Крушевский болай дигән: «Тел үсешенең төп законы ул – уй-фикер дөньясының сүзләр дөньясы белән тәңгәл килүе». М.З.Зәкиев тел үсеше төшенчәсенең янә бер сыйфатын аерым билгели: «... теләсә нинди әдәби телнең чын-чыннан үсеше аның гомумхалык сөйләме теленә якынлык дәрәҗәсе белән билгеләнә» («Туган тел үсеше», Казан, 1969, 53 б.). В.Х.Хаков телнең төрле иҗтимагый шартларга карап активлашуын, функцияләренең киңәюен һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, стиль төрләренең ишәюен бу төшенчәнең асыл сыйфатлары рәтенә кертә («Татар әдәбият теленең совет чорында үсеше», Казан, 1985, 3б.).

Мөхәммәт Мәһдиевнең теле – милли байлыгыбыз. Аның эсселәрендәге сурәтләү чараларының палитрасы, тел бизәкләре татар әдәбиятының кабатланмас һәм тутыкмас көзгесе сыман.

Әдип иҗатына килгәндә, әйтеп киткән тел үсеше сыйфатларын табып була. Кыскача әйткәндә, бу: 1) чынбарлыкны төгәл сурәтләү; 2) гади сөйләм элементлары аша персонажларның портретларын сурәтләү; 3) телнең функциональ яктан кулланышын киңәйтү.

Эссе – ул әдәби-публицистик жанрларның (тасвирнамә, парча, очерк) бер төре. Димәк, аны, бер яктан, татар журналистикасы жанрларының өч буынлы зур системасының (хәбәри, аналитик, әдәби-публицистик) һәм, икенче яктан, әдәби-публицистик жанрлар чылбырының аерылгысыз, өзелмәс бер буыны дип карарга кирәк.

Эссе жанры үткән гасырның азагында өлгереп җиткән мөстәкыйль жанр буларак күзәтелә. Соңгы елларда ул актив үсеш алды. Жанр буларак аның чалымнарын татар әдәбияте, публицистикасы һәм журналистикасының борынгы – башлангыч чорлары әсәрләреннән үк күзәтеп була.

Барлык стиль чараларын бер бөтен итеп оешытырып, әсәрне сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрүче – автор үзе. Бу М.Мәһдиевнең эсселәрендә ачык чагыла. Автор сүзе эсседә күп төрле мәгънәләрдә кулланыла. Ул әсәрне иҗат итүче дә, башка геройлар белән укучыга персонаж да, хикәяләүче дә, лирик герой да, сурәтләүче дә. М.Мәһдиев автор буларак та, үзе герой булып та әсәрнең һәр сүзендә, һәр җөмләсендә чагыла. Халык тормышын сурәтләү, аның төрле катламнарына сүз бирү М.Мәһдив эссесе теленә җанлы сөйләм стихиясен бирә.

Язучы телендәге стиль алымнары үзенчәлекле. Аның йөгерек метафоралы, шаян, шук, җор һәм шул ук вакытта итагатьле стилен башкалар белән бутау мөмкин түгел. Аның эсселәрен тел һәм стиль үзенчәлекләрен без «Остаз» эссесе мисалында билгеләдек.

«Остаз» эссесе гаять әһәмиятле теманы яктырта. Әлеге әсәрдә сүз трагик язмышлы, гаҗәеп талантлы методист-педагог, урыс теле һәм әдәбият укытучысы Хәлим Искәндәрев турында бара кебек. Биредә төп геройның татар балаларына нәтиҗәле итеп урыс телен укытуы турындагы эш алымнары сурәтләнә. Ләкин, белгәнебезчә, М.Мәһдиев «шәхсилектән» «гомумилеккә» ирешү остасы. Бер караганда, шәхси генә бер вакыйга, хикәя бу. Автор үз остазына булган мөнәсәбәтен, рәхмәтен белдерә. Әмма нәтиҗәдә, соңгы бүлектә, автор гомуми проблемаларга килеп төенләнә. М.Мәһдиев элекке татар зыялысы нинди булганын күрсәтә. Ә татар зыялысы бер генә тел белмәгән! «Бүген безгә урыс теле нәрсәгә, төрек телен бирү кирәгрәк диләр. Без рус чолганышында яшибез. Дүрт ягында да рус кешесе булгач, аның белән сәүдә итешмичә, алыш-биреш итмичә, гыйлем-мәгърифәт өлкәсендә казанышларны уртаклашмыйча яшәү мөмкин түгел», – ди автор.

Автор эсседә Хәлим Искәндәревнең трагик тормышы, педагогик системасы нигезендә «татар баласының русның үзе кадәр, мөмкин булганда, үзеннән дә уздырыбрак рус телен белү кирәклеге» турындагы фикер уздыра.

Әсәрдәге эссе жанрына гына хас үзенчәлекләрне күзәтеп үтик элек. **Публицистик чаралардан** башлыйк. Эссе бит ул документаль әсәр. Анда бер **факт** та уйлап чыгарылмый. Хәлим Искәндәрев чыннан да Арча педагогик училищесында рус теле һәм әдәбиятын укыткан. Ул М.Мәһдиевнең остазы, укытучысы. Бу – реаль факт. Бу эссесендә автор шушы фактка карата гомуми карашны да, шәхси карашын да чагылдыра.

Фактик материал белән эш итүдә эссечыларның «мине» **детальләр** табып куллана белүдә көчле чагыла. Бу эссесендә М.Мәһдиев «кабатланам» ди. Бу деталь бит аныкы гына, башка авторныкы була алмый.

Иң мөһиме шунда, детальләр очраклы түгел, укучыны җәлеп итү өчен генә кертеп кыстырылган «ялтыравыклар» түгел. Алар бер нәтиҗәне истә калдыру өчен кирәкле чаралар. М.Мәһдиевнең «Остаз»» эссесендә автор хикәяләү процессында кирәкле урыннарда Тукайдан цитаталар еш китерә: «Рәхмәт аңа, өйрәтте бер яхшы нәрсә», «Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла...», «Мондый хәлгә сабриталмас, булса да адәм дию», «Әгәр, хәлфә, мин дә шулай надан булсам, Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам...» .

Эссеның **әдәби тасвир чараларына** килгәндә, эсседа барлык әдәби-публицистик жанрларга хас чаралар кулланыла. Тик бер үзенчәлеге бар – алар авторның шәхси табышы булып кабул ителергә тиеш. Бу чара гомумкешелек казанышы булса да, укучы аны, бер үк вакытта, нәкъ менә шушы авторныкы дип хис итеп, шул ачыш тәэсиреннән рухлана ала.

Әдәби сөйләм һәрвакыт мәгънә белдерүгә хезмәт итә. Әдәби әсәрне кәгазьгә төшергәндә, автор башта сүзләр сайлый. Әсәрдә аерым бер сүзләр туры, номинатив мәгънәдә кулланылса, икенчеләре күпмәгънәлелеккә ирешү чарасына әверелә. Сүзләрнең күчерелмә мәгънәләр белдерә алу сәләтенә, җөмләдә төрлечә урнаша алу мөмкинлегенә, авазлар яңгырашына һ.б. карап, әсәр теленең сурәтлелеге хасил була. Шуңа күрә тел-сурәтләү чаралары да язучы стилен билгеләүче доминантага әверелгә мөмкин. Без аларны дүрт төркемгә аерып карарга булдык.

**Лексик чаралар** дип дөрес сайлау һәм урынлы куллану аркасында сурәт тудыручы сүзләр атала. Сүз һәм гыйбарәләрнең үз үзенчәлекләреннән чыгып, аларны төркемләргә мөмкин.

1. Мәгънә охшашлыгына яки аерымлыгына нигезләнгән лексик чаралар (синонимнар, антонимнар, омонимнар, сүз уйнату). «Остаз» эссесендә без бер җөмләдә кулланылган синонимнар таптык: «җайсыз-уңайсыз», «почмагында-чатында», «арып-талып», «никадәр сытылу, ватылу, имгәнү». Автор синонимнарны бер үк әйбер яки күренешләрне белдереп, аның төрле мәгънә чагылдыру өчен кулланган.

2. Сүзләрнең тарихына һәм географиясенә бәйләнешле лексик чаралар (архаизмнар, тарихи сүзләр, неологизмнар, диалектизмнар, гади сөйләм сүзләре). Алар арасында эсседә архаизмнар еш очрый. Мәсәлән, ибтидаи (башлангыч), җөзьэ, көрә, мөкәммәл. Бу искергән, кулланылыштан төшеп калган сүзләр. XX гасырга кадәрге әдәбиятта кулланылган күп кенә сүзләр бүгенге укучы өчен архаизм булып тора.

Шулай ук эсседән вульгаризмны да аерып чыгарырга була: «үзенең «учредилка» гөнаһын каплар өчен; иң «ехидный»; «иң актык чутта гына».

Калькалар: «жалу» бирергә дип райком бинасына киттек». Бу башка телдәге үрнәккә охшатып төзелгән сүз.

Лексик чаралар, барынан да элек, тексның субъект оештырылышын тикшергәндә ярдәмгә килә. Геройлар сөйләвен яки сөйләшүен, хикәяләвен бәяләү лексик составка карап башкарыла.

**Троплар яки ассоциатив сурәтләү чаралары** дип күчерелмә мәгънәне төрле әйберләр, күренешләр, предметлар арасындагы бәйләнеш аша барлыкка китерә торган гыйбарәләргә әйтәләр. Алар образ тудыру, тесктның тәэсир көчен арттыру, сурәтләнә торган күренеш-халәтне укучы күз алдына төгәл китереп бастыру өчен хезмәт итәләр.

Чагыштырулар – нинди булса да күренешне башка күренешкә охшату ярдәмендә барлыкка килгән сурәтләү чарасы: «башы эскерт шикеллерәк», «адәм баласы эт баласы икән. Чыдыйбыз!», «мендәр тышы (бетләрдән),

әйтерсең бөрчекле материал», «кош теледәй кәгазь», «без – ачлар дөньясы – күтәрелдек», «Димәк, «учредилкачы», халык дошманы Г.Ибраһимовның дусты, КУТВда халык дошманы Галимҗан Нигъмәтине укыткан, мәдрәсә җимеше, мулла малае Хәлим Искәндәрев белән бер коллективта эшләгәннәр болар. Бүре белән сарык бер абзарда. Кәҗә белән кәбестә бер бакчада. Питон белән куян бер читлектә...»

Метафора – күренешләрнең охшашлыгына яки каршылыгына нигезләнеп, яшерен чагыштыру хасил иткән сурәтләү чарасы. «Остаз» эссесендә шундыйлары очрый: «баштан пар чыга», «хезмәт халкының канын эчүгә күчәләр», «сугыш иттурагычына кереп шәһит китәр өчен», «агач елмаю белән елмайды», «остазыбыз янды», «шигырь юлларын теткәләп», «тимер тавышлы, чуен күңелләргә, агач чырайлы директорларга».

Эпитетларга килгәндә, эсседә түбәндәгеләре кулланыла: «ач гәүдәләр», «яшьлегендә «Ачлык» исемле патша тарафыннан яньчелгән авыл малае».

Гипербола – чиктән тыш арттыруга нигезләнгән стилистик сурәтләү чарасы. Ул күренешне, характерны, ситуацияне гадәттән тыш күпертеп, сурәтнең тәэсир көчен арттыра. Мәсәлән, «Остаз» эсесендә «туный башлады», «дәрестә ул кисәтү ясаганда студентларның битләре агарып кала иде» кебекләре очрый.

Шулай ук эссе эчендә фразеологизмнар ассоциатив сурәтләү чарасы вазифасын башкаралар. Бу очракта фразеологизм төшенчәсе халык телендәге мәкаль-әйтемнәрне дә, үткен, образлы гыйбарәләрне дә үз эченә ала. Тикшерелә торган эсседән без «җиң сызганып тикшерелерлек», «минем көймәм комга терәлде» кебекләрне таптык.

Эсседә М.Мәһдиев юмор элементы да кертеп җибәрә. Ул анекдот бирә. «Бер татар ашханәгә кергән. Тыңлап утыра: кешеләр две каши, один борщ, одни щи, три стакана чая сорыйлар, ә моның нибары ике стакан чәй эчәсе бар. Ничек әйтергә? «Два стакана»мы, «две стакана»мы? Татар, әгәр телне белмәсә, хәйләгә керешә. Бу – электән килгән. Официантка аның янына килгәч, татар агай болай ди:

Три стакана чая, один унесите обратно...».

**Стилистик фигураларны** караганда, шуны әйтергә кирәк: алар сүзләрнең фразага һәм җөмләгә оешу үзенчәлекләренә нигезләнгән сурәтләү чаралары.Аларны дүрт төркемгә аеру кабул ителгән: кабатлауга нигезләнгән фигуралар, сүзләрнең сөйләмдә гадәти булмаган тәртибеннән хасил булган чаралар, мәгънә каршылыгы барлыкка китерүчеләр, автор ихтыярын чагылдыручылар.

Беренче төркемгә керә торган, иң киң очраучы чара – кабатлау. Әсәрдә сүзләр, гыйбарәләр, җөмләләр, кисәкләрнең нинди дә булса кагыйдәгә нигезләнмичә кабатлануы ул. «Остаз»да очраган кабатлау – «Хәлим Фәттахович... Хәлим ага... ләх исерек иде. Әйе, ул ләх исерек һәм....». Бу алым әсәрнең тәэсирлеген, андагы мәгънәви һәм хисси кыйммәтне көчәйтү, язучы теләгән урыннарга укучының игътибарын юнәлтү өчен кулланыла.

Сүзләрнең сөйләмдә гадәти тәртибе үзгәрү шулай ук бер төркем фигуралар хасил итә. Безнең эсседә инверсия күренеше бар. Инверсия – сөйләмнең тәртибен үзгәртү ярдәмендә яңа эмоциональ төсмер бирү. Мәсәлән, «Атлый түбән карап Гариф Ахунов, директор янына кергәч сүзне кем башлар икәнлеге турында бәхәс кора. Атлый тәбәнәк таза Габделхәй Миннебаев».

Автор ихтыярын чагылдыручы фигуралар, исеменнән үк күренгәнчә, автор позициясен, мөнәсәбәтен белдерүгә хезмәт итә. Аларга риторик сорау, риторик өндәү, риторик эндәш – ягъни лирик герой яки хикәяләүченең укучыга, әсәрдә сурәтләнгән образга эндәшүен кертәләр. «Остаз» эссесендәге риторик сораулар: «Татар баласы рус теленең кайсы почмагында, чатында сөртенә? Өйрәтүне дөрес сөйләшүдән түгел, хаталардан башларга.», «Ә чыгыш килешендә саннар нишләп кенә бетмиләр?», «Бет шулкадәр хәрәкәтчән, үрчемле дип кем уйлаган?», «Без шуның өчен сугыштыкмыни, бу яшь буынны бет ашасын өчен Прагага, Берлингача барып җиттекмени?», «Искәндәрев кебек зур эрудицияле, культуралы кешеләрне төрмәдә нишләтәләр икән?».

Риторик өндәү: «Кая инде ул безгә аны тәрҗемә итү!», «Татар башы моңа ничек җитсен!», «Менә татар өчен авыр урын кайда!», «Ул рәсемдә безнең авыл егетләре булмый калмас!», «И бичара татар егетләре!».

Стилистик чаралар, фонетик чаралар кебек үк, интонация тудыруда катнаша. Алар текстның яңгырашын тудыру өчен кирәк.

Әсәр телен авазлар яңгырашы ягыннан оештыру фоника, ә шунда катнашучы чаралар **фонетик чаралар** дип атала. Фонетик чаралардан «Остаз» эссесендә без охшату алымын таптык. Охшату улниндә булса күренешне авазлар ярдәмендә күз алдына бастыру. Мәсәлән, эсседә кулланган охшатулар: «рюкзакны «лаф» итеп кертеп куйды», «пыф-пыф» итеп авыр сулады», «чарт-чорт килеп ак чыршы утыны яна».

Шулай итеп, «Остаз» эссесе теленең сурәтләү чаралары ярдәмендә баетылган, матурайтылган булуы, риторик стильгә ия икәнлеге ачыклана. Төп сурәтләү чарасы буларак градация сайланган. Һәр күренештә М.Мәһдиев бер-берсен көчәйтә баручы, бер-берсенә өстәлә торучы сурәт тудыра.

Эссеның композиция-төзелеш үзенчәлекләре турында берничә сүз. «Остаз» эссесе ун бүлекчәдән тора. Һәр бүлекчә төрле еллар аралыгында үткән вакыйгаларны сурәтли. Биредә дә эссеның әдәби публицистик жанрга каравы үзен сиздерә. Публицистика – документаль нигезле иҗат, анда бер нәрсәне дә – бер факт, детальне, вакыйганы, күренешне, шәхесне, – уйлап чыгарырга, үзгәртергә тиеш түгел, ә композицияне, сюжетны нәкъ очерктагы кебек уйлап чыгарырга «рөхсәт ителә».

М.Мәһдиев эссене гади, сөйләм теле белән язган. Бу эссе аның куен дәфтәренә үзе өчен генә язып куелган кисәкләрне, истәлекләрне дә хәтерләтә. Бу алым укучыга эссеның теле якын, аңлаешлы булсын өчен алынган. И.М.Низамов сүзләре буенча, иң элек «эссе сөйләме – ул ана телен дөрес, ачык, образлы, аһәңле куллануның иң югары таләпләренә җавап бирергә тиешле

сөйләм. Анда тел ярлылыгына, тел кытыршылыгына, шапшаклыгына һич тә юл куелмый». Безнеңчә, М.Мәһдиев эссесе бу таләпләргә җавап бирә.

**Әдәбият**


1. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Яр Чаллы, 1997. 128 б.
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 215 б.
3. Әхмәдуллин А.Г. Әдәбият белеме сүзлеге. Казан: Тат. кит.нәшр., 1990. 238 б.
4. Бәширова И. Сүз белән сүрәт ясау. Казан: Тат.кит.нәшр., 1974.- 176 б.
5. Бәширов Ф. Сөйлә, каләм!. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. Казан: Тат.кит. нәшр., 2001. 143 б.
6. Галимуллин Ф.Г. Офыкларны алдан күреп. Тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Тат.кит.нәшр., 1995. 200б.
7. Гәрәй Й. Сүз асылы. Тел хикмәтләре. Уфа: Мәгариф, 2001. 179 б.
8. Заһидуллина Д. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми бәлем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2005.111 б.
9. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255б.
10. Мәһдиев М.Ачы тәҗрибә. Казан: Тат.кит.нәшр., 1985.467 б.
11. Мәһдиев М. Йомгаклау дәфтәре / М.Мәһдиев /Казан журналы,. 1994, №3-4.
12. Метод, стиль, жанр (җыентык). Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. 224 б.
13. Мөхәммәдиев Р., Ахунов Г. «Кеше китә – җыры кала»: Повестьлар, истәлекләр, хатлар.Казан: «Татар китабы» нәшр., 1996. 288 б.
14. Низамов И. Татар эссесы: кичә, бүген, иртәгә / И.Низамов //Мәдәни җомга, 25 май, 2007 ел, 12 б.
15. Низамов И.М. Уем – тел очында. Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. 475 б.
16. Хаков В.Х. Татар әдәби теле: Стилистика. Казан: Тат. кит. нәшр., 1999. 304 б.
17. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. Казан: Мәгариф, 2000, 351.б.